| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**11.12.2020** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 2430** |
|---|---|---|

Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законының үз көчен югалтуын тану турында » 2020 елның 19 ноябрендәге 75-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында» Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 26 октябрендәге 2258 номерлы карары белән расланган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә түбәндәге эчтәлекле 9 юлны исемлектән төшереп калдырып, үзгәреш кертергә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| 9 | **2.14 статья ТР КоАП** | Тартмый торган тәмәке әйберләре белән Татарстан Республикасы территориясендә күпләп һәм ваклап сәүдә итүне тыюны бозу. | - «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ начальнигы;<br>- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе »МКУ начальнигы урынбасары;<br>- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | баш белгече;<br>- «Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының административ-техник инспекциясе идарәсе» МКУ әйдәп баручы белгече;<br>- Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлеге начальнигы;<br>-Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлегенең баш белгече;<br>-Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының җәмәгать куркынычсызлыгын тәэмин итү бүлегенең әйдәп баручы белгече. |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлеге начальнигына Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.В.Старостинга йөкләргә.

Җитәкче И. Р. Ганиев